СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«25» июль 2024 ел** **№ 292**

**«Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» 2021 елның 20 апрелендәге 55 номерлы Арча район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә, Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе эшчәнлеген оештыруны камилләштерү максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» 2021 елның 20 апрелендәге 55 номерлы Арча район Советы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
___________ел, №__
карарына 1 нче кушымта

Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, Арча район Советы рәисе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Вильданова Чулпан Рифатовна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторы мөдире, комиссия секретаре; |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Батталова Резеда Хатиповна | - Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгы; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Митина Ольга Геннадиевна | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге баш белгече; |
| Галимова Светлана Петровна | - «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы " МКУ җитәкчесе; |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советы аппаратының оештыру-гомуми бүлеге башлыгы. |